## КЫР КАЗЛАРЫ АРТЫННАН

*(Шул исемдәге пьесадан)*
*Мәсгут Имашев көе*
*Илдар Юзеев шигыре*

Кыр казлары артыннан
Биеклеккә омтылам.
Хыялыма китәр идем
Кыр казлары артыннан.

Кыр казлары артыннан
Китәр идем, тартынам.
Үз-үземне бәйләгәнмен
Хыялым канатыннан.

Кыр казлары артыннан
Очарга дип талпынам.
Тик очалмыйм, карап калам
Кыр казлары артыннан.